ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 476-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 476-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2120-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), 2023, № 56 (I өлеш), «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Россия Федерациясе Салым кодексының $346^{20}$ статьясының 1 һәм 2 пунктларына ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе субъектлары законнары белән салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен түбәнәйтелгән салым ставкалары билгеләнергә мөмкин.

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Закон проекты белән Икътисади эшчәнлек төрләренең 62 «Компьютер программа тәэминатын эшләү, әлеге өлкәдә консультация хезмәтләре һәм башка ярдәмче хезмәтләр» һәм 63 «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге эшчәнлек» гомумроссия классификаторы кодларына туры килгән югары технологияләр өлкәсендәге технопарк резидентлары өчен ташламалы салым ставкаларын өч елга озайту тәкъдим ителә.

Закон проекты тәкъдим иткән үзгәрешләр Россия Федерациясенең башка субъектларыннан Татарстан Республикасына мәгълүмати технологияләр өлкәсендә яңа компанияләрне җәлеп итүгә, Татарстан Республикасында кече һәм урта бизнес компанияләренең тотрыклы яшәү сәләтен саклауга, тулаем республиканың инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән.

Бүгенге көндә республикада салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланган салым түләүчеләр өчен стандарт салым ставкасы:

керем рәвешендә салым салу объекты белән - 6 процент;

салым салу объекты чыгымнар күләменә киметелгән керемнәр рәвешендә - 10 процент.

Моңарчы күрелмәгән санкцияләр басымы шартларында Татарстан Республикасы территориясендә технопаркның стартапларын һәм резидентларын югары технологияләр өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның ташламалы шартларын саклау юлы белән саклау таләп ителә.

Моннан тыш, ИТ-тармакка ярдәм итүнең төбәк чаралары «Цифрлы икътисад» милли программасы кысаларында Россия Федерациясе субъектлары арасында цифрлы трансформация җитәкчеләре рейтингында Татарстан Республикасы позициясенә йогынты ясый торган күрсәткечләр исемлегенә кертелде.

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү 2024-2026 елларда югары технологияләр өлкәсендә технопарк стартаплары һәм резидентлары эшчәнлегеннән 490 млн сум күләмендә төшеп калучы керемнәргә китерәчәк.

2021 елда 56 компания түбән салым ставкасын кулланган. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча, салым ставкасын киметү сәбәпле салым кермәүнең гомуми суммасы 81 378 мең сум тәшкил иткән.

2022 елда салым кермәү суммасы 133 821 мең сум тәшкил итте, шул ук вакытта 92 компания түбәнәйтелгән салым ставкасын кулланды. 2023 елда салым кермәү суммасы 147 203 мең сум күләмендә бәяләнә.